**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы**
**Яңа Элмәле авыл җирлеге гражданнары җыены**
**КАРАРЫ**
**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы Яңа Элмәле авыл җирлегенең Яңа Элмәле торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**№4** **27.10.2023 ел**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Чирмешән муниципаль районының Яңа Элмәле авыл җирлеге Уставының 22 ст., Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Яңа Элмәле авыл җирлеге Советының 2019 елның 11 июнендәге «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль район Советының 2018 елның 24 сентябрендәге «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Яңа Элмәле авыл җирлеге составына керүче торак пунктта гражданнар җыенын уздыруга әзерлек тәртибе турында» гы нигезләмәне раслау турында» №94 карарына үзгәрешләр кертү хакында» №132 карары нигезендә КАРАР КЫЛДЫ:

1. 2024 елда муниципаль районның Яңа Элмәле авыл җирлегенең Яңа Элмәле торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 800 сум күләмендә үзара салым кертергә көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, 1 төркем инвалидлардан, балачактан инвалидлардан, 85 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк кешеләрдән, күп балалы аналардан, Луганск халык республикасы һәм Донецк халык республикасы махсус операциясендә булган затлардан тыш

2. Алынган чараларны җибәрергә:

- җәйге һәм кышкы чорда юлларны төзекләндерүгә, карап тотуга, хезмәт күрсәтүгә чыгымнар (юл кырыйларын чабу, юлларны грейдлау, кышкы чорда урамнарны кардан чистартуга, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр, элмә һәм тагылма җиһазлар сатып алуга, тракторчыга хезмәт күрсәтүгә түләү) Яңа Элмәле торак пунктында;
- Яңа Элмәле торак пунктында урамнарны яктырту, монтажлау, ремонтлау, карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;
- Яңа Элмәле авыл җирлегендә урам-юл челтәрен төзекләндерү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу, вак таш сатып алу;
- мотопомпа сатып алу
- җиңел автомобиль өчен прицеп сатып алу
- генератор сатып алу
- Яңа Элмәле авыл җирлегендә яшәүчеләргә һәм аларның мөлкәтенә куркыныч тудыручы агачларны кисү (хезмәт өчен түләү һәм югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле кораллар сатып алу).

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Яңа Элмәле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

**Гражданнар җыенында рәислек итүче**
**Яңа Элмәле авыл җирлеге башлыгы И.М. Җамалтдинов**